**Бер җылы сүз...**

Һәр кешенең үз язмышы була,

Сагышлардан җаннар күшегә.

Шундый чакта күңел күтәрергә

Бер җылы сүз җитә кешегә.

Ихтирамлы булыгыз карт-корыга,

Шәфкать кылыгыз булган кадәрле.

Кайчагында шифа булып куя,

Бер җылы сүз – яшәү ядкаре.

Язмышлардан узмыш юк икәнен,

Белми түгел кеше дигәнең.

Исән чакта кирәк өлкәннәргә

Сәлам биреп башың игәнең.

Без дә озын, кара чәчле идек...

Хәзер ап-ак чәчле әбиләр.

Йорт эшләрен эшли алмасак та,

Булышырбыз үстерергә сезгә бәбиләр!

Хөрмәтле авылдашларым, өлкән буын кешеләре!

Сезне Өлкәннәр көне белән чын күңелдән котлыйм! Сезгә ныклы сәламәтлек, чиксез шатлык, балаларыгыз-онықларыгызның игелеген күреп яшәвегезне телим!

*Зур ихтирам белән, Фәния Латыпова (Каримова). Красноярск крае, Железногорск шәһәре, 2021 ел, сентябрь*